КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 август г.Казань № 921

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарына квота билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 ел, 4 май, 170 нче карары белән расланган Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы эш бирүчеләрдә инвалидлар өчен эш урыннарына квота билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарына квота билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 ел, 4 май, 170 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 декабрь, 954 нче; 2015 ел, 18 июль, 524 нче, 2020 ел, 18 март, 201 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы эш бирүчеләрдә инвалидлар өчен эш урыннарына квота билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Инвалидларны эшкә кабул итү өчен квота «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $13^2$ статьясы, «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнә.

Инвалидларны эшкә кабул итү өчен квота ел саен, 1 февральгә кадәр, алдагы елның IV кварталында хезмәткәрләрнең уртача исемлек санынннан чыгып, эш бирүче тарафыннан исәпләнелә.

Инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннары минималь санда түбәндәгеләр тәшкил итә:

гомуми алганда алтыдан алып 15 кә кадәр квоталы эш урыннары саны - бер махсус эш урыны;

гомуми алганда 15 тән алып 30 га кадәр квоталы эш урыннары саны - ике махсус эш урыны;

гомуми алганда 30 дан артык квоталы эш урыннары саны - өч махсус эш урыны.

Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен минималь эш урыннары инвалидларны эшкә кабул итү өчен квоталар исәпләү белән бер үк вакытта эш бирүче тарафыннан исәпләнелә.

Узган айда хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны кимегән очракта, эш урыннарында хезмәт шартлары хезмәт шартларын махсус бәяләү нәтиҗәләре буенча зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларына кертелгән хезмәткәрләрдән тыш, инвалидларны эшкә кабул итү өчен квота яңадан исәпләргә тиеш.

Инвалидларны эшкә кабул итү өчен квоталарны исәпләп чыгару хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны үзгәрү булган айдан соң килүче айның беренче числосыннан эш бирүче тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Инвалидларны эшкә кабул итү өчен квоталарны исәпләү максатларында хезмәткәрләр саны Россия Федерациясенең башка субъектларында урнашкан эш бирүче филиаллары һәм вәкиллекләре хезмәткәрләрен исәпкә алмыйча, хезмәткәрләрнең уртача исемлек санынннан чыгып билгеләнә.

Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең башка субъектында урнашкан эш бирүче филиалларына һәм вәкиллекләренә инвалидларны эшкә алу өчен квота мондый филиаллар һәм эш бирүченең вәкиллекләре хезмәткәрләренең уртача исемлек санынннан чыгып билгеләнә.

Эш бирүче инвалидларны эшкә кабул итү өчен квотаны агымдагы ел дәвамында, аның мөмкин булган яңадан исәпләвен исәпкә алып, үтәргә тиеш.»;

2.5 пунктта «хезмәт шартлары буенча эш урыннарын аттестацияләү нәтиҗәләренә яисә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.7 – 2.9 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Инвалидларны эшкә кабул итү өчен квотаны исәпләгәндә вакланмалы санны түгәрәкләү, исәпләнгән квотаның күләме берәмлектән кечерәк булган очракта, квотаның әһәмияте тигез берәмлек итеп кабул ителә.»;

2.11 һәм 2.12 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

2.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.13. Инвалидларны эшкә алу өчен квоталар кысаларында булдырылган махсус эш урыннарын ликвидацияләү Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре (алга таба - эш белән тәэмин итү үзәкләре) һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм

социаль яклау министрлыгы (алга таба - Министрлык) белән килештереп башкарыла.»;

2.14 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.15 һәм 2.16 пунктлар өстәргә:

«2.15. Инвалидларны эшкә кабул итү өчен квота эш бирүче тарафыннан инвалидлар белән хезмәт мөнәсәбәтләрен билгеләнгән тәртиптә инвалидлар белән рәсмиләштерелгән очракта, эш бирүче инвалидларны эшкә алу квотасы нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру бурычларын үтәгән очракта, башкарылган эш бирүче санала.

2.16. Эш бирүче инвалид белән хезмәт мөнәсәбәтләрен билгеләнгән тәртиптә теләсә кайсы эш урынына рәсмиләштерү инвалидларны эшкә кабул итү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән очракларда һәм тәртиптә квота үтәү булып санала.»;

3.1 – 3.3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Эш бирүчеләр инвалидлар өчен эш урыннарын квоталауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруда катнашалар, аларны инвалидларны эшкә алу өчен квоталар чикләрендә бүлеп бирелгән яисә алар төзегән эш урыннарына эшкә урнаштыру юлы белән, шул исәптән махсус эш урыннары да.

Инвалид белән хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштергәндә инвалидларны эшкә кабул итү квотасы түбәндәге очракларда эш бирүче тарафыннан башкарылган санала:

эш бирүчедә инвалид белән эш урынына хезмәт шартнамәсе (шул исәптән вакыты чикләнгән) булу;

инвалид һәм оешма, индивидуаль эшкуар арасында, инвалидларның иҗтимагый берләшмәләрен һәм алар төзегән оешмаларны да кертеп, хезмәт килешүе булу, шул исәптән устав (җыелма) капиталы инвалидларның башка оешма яки индивидуаль эшкуар белән инвалидларны эшкә урнаштыру турында килешү төзегән инвалидлар иҗтимагый берләшмәсе кертеменнән тора (алга таба - килешү).

Инвалидларга инвалидны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы нигезендә хезмәт шартлары тудырыла.

3.2. Эш бирүчеләр ай саен, хисап аеннан соң килүче айның бишенче числосына кадәр, инвалидларны эшкә алу өчен квота нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яки бүлеп бирелгән эш урыннары булу турында, шул исәптән әлеге эш урыннары турында белешмәләр булган локаль норматив актлар турында мәгълүматны да кертеп, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкны эш белән тәэмин итү максатларында оператив мониторинг уздыру турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 24 номерлы боерыгына (алга таба - Россия Хезмәт министрлыгының 2022 елның 26 гыйнварындагы 24 номерлы боерыгы) 5 нче кушымта нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 25 статьясындагы 3 пунктында каралган белешмәләрне һәм мәгълүматны эш бирүче тарафыннан тапшыру тәртибе хакында» 2021 елның 30 декабрендәге 2576 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 25 статьясындагы 3 пунктында каралган белешмәләрне һәм мәгълүматны эш бирүче тарафыннан тапшыру тәртибе нигезендә инвалидларны эшкә алу өчен квоталар үтәү хакында мәгълүматны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырырга тиеш.

3.3. Эш бирүчеләр инвалидларны эшкә алу өчен квоталар чикләрендә инвалидларны эш урыннарына эшкә урнаштыру хокукына башка эш бирүчеләрдә килешүләр төзү юлы белән ия.

Килешүдә эшкә кабул ителергә мөмкин булган инвалидлар саны, хезмәт өчен түләү чыгымнарын каплау шартлары, инвалидның эш урынын җиһазлау шартлары, инвалид өчен эш урыны алу мөмкинлеген тәэмин итә торган махсус шартлар булдыру зарурлыгы, кирәк булганда, инвалид эшкә урнашкан оешмада (шәхси эшмәкәрдә) эшкә урнашканда озатуга бәйле чыгымнарны компенсацияләү шартлары, килешү гамәлдә булу сроклары, хокуклар, якларның бурычлары, өзү шартлары һәм башка шартлар билгеләнә.

Инвалид эшкә урнаштырыла торган эш бирүчегә инвалидларны эшкә алу өчен квота билгеләнгән булса, килешү нигезендә эшкә урнаштырылган инвалидлар квота исәбеннән исәпкә алынмый.»;

3.4 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.5 һәм 3.6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Инвалидларны эшкә алу өчен квота исәбенә эш белән тәэмин итү эш белән тәэмин итү үзәкләре юнәлешләре буенча да, мөстәкыйль рәвештә дә эш бирүчеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.6. Эш белән тәэмин итү үзәкләре инвалидларны эшкә алу өчен квоталар чикләрендә эш белән тәэмин итү үзәге юнәлешләре буенча эшкә урнашкан гражданнарны исәпкә ала.

Инвалидларны эшкә кабул итү өчен квота чикләрендә мөстәкыйль рәвештә эшкә урнашучы гражданнарны, шул исәптән махсус эш урыннарына, исәпкә алу, әлеге мәгълүматны алга таба ай саен эш белән тәэмин итү үзәкләренә Россия Хезмәт министрлыгының 2022 елның 26 гыйнварындагы 24 номерлы боерыгына 5 нче кушымта нигезендә турыдан-туры эш бирүче тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

4.1 пунктта «билгеләнгән квоталарның» сүзләрен «инвалидларны эшкә алу өчен квоталарның» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Эш бирүчеләрнең буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар, инвалидларны эшкә алу өчен квоталар нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яисә бүлеп бирелгән эш урыннары булу турында мәгълүмат бирүләрен, әлеге эш урыннары турында белешмәләр булган локаль норматив актлар турындагы мәгълүматны да кертеп, тикшереп тору, инвалидларны эшкә алу өчен квоталар үтәү мәшгульлек үзәкләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

әлеге Нигезләмәнең 3 нче һәм 4 нче кушымталары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карар (әлеге карарның 2022 елның 1 сентябреннән үз көченә керә торган 1 пунктының дүртенче - унберенче, егерме сигезенче - утызынчы, утыз өченче - утыз бишенче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин